Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 17 (30)

31 май 2012 ел

## • Ике авыз сүз

Татарстан Республикасында 2010-2015 елга «Киләчәк» – «Будущее» мәгариф үсеше стратегиясен тормышка ашыру кысаларында **«БЕЗНЕҢ ЯҢА УКЫТУЧЫ» КОНКУРСЫНЫҢ ИКЕНЧЕ ЭТАБЫ СТАРТ АЛДЫ**. Ул вуз студентларын, яшь аспирант һәм кандидатларны мәгариф учреждениеләренә эшкә урнаштыруны максат итеп куя. 28 май көнне Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгында югары уку йортларында әлеге программаны тормышка ашыру буенча узган җыелышта КФУ педагоглары да катнашты. Узган ел безнең уку йорты катнашучылар саны буенча лидер булды. Шулай ук 29 май көнне Педагогика һәм психология институтында ТР ның Мәгариф һәм фән министры урынбасары А.Поминов катнашында КФУ Укыту-методик үзәгенең утырышы узды. Анда өзлексез педагогик белем бирү концепциясе каралды. Аның төп бурычы булып укытучылар әзерләү сыйфатын яхшырту, практикага зур игътибар бирү тора. Казан университеты исә республикада педагогик кадрлар әзерләү буенча төп уку йорты санала.

• • • •

25 май көнне КФУга Британиянең (Лондон) Король фәнни оешмасыннан вице-президент, халыкара эшләр буенча киңәшче, **ПРОФЕССОР МАРТИН ПОЛЯКОВ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘГЕ ДЕЛЕГАЦИЯ КИЛДЕ**. Мартин Поляков Ноттингем университетында да химия фәне профессоры булып тора. Бөекбританиядәге әлеге оешма 1660 елда оеша һәм фәнни-тикшеренү эшләре алып бара торган алдынгы үзәк булып тора. Визит барышында кунаклар уку йортыбыз тарихы музее һәм Казан химия мәктәбе музее белән танышты. Тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыйпов белән очрашу барышында, КФУ белән Король фәнни оешмасы арасында табигый фәннәр, ориенталистика, ислам динен өйрәнү, дөньякүләм икътисад, фәлсәфә өлкәсендә хезмәттәшлек итү турында килешенде. Мартин Поляков Ноттингем университеты исеменнән КФУ белән укытучылар һәм студентлар алмашы өлкәсендә хезмәттәшлек итү теләген дә җиткерде.

• • • •

Россиядә органик химиянең бәллү бишеге булган **КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ ХИМИЯ ЛАБОРАТОРИЯСЕ ОЕШУГА 175 ЕЛ**. Биредә күп еллар дәвамында күренекле галимнәр эшли. К.Клаус, Н.Зинин, А.Бутлеров, В.Марковников, А.Зайцев, Ф.Флавицкий, Е.Вагнер, С.Реформатский, А.Арбузов, Б.Арбузов, Г.Камай кебек халыкара таныш химикларның ачышлары, аерым хезмәтләре әле бүген дә дөньякүләм химия фәненең алтын фондын тәшкил итә. Тулырак *http://www.planetpics.ru/journals/69#1* сайтыннан укый аласыз.

• • • •

30 май көнне «Казан» милли-мәдәни үзәгендә ел саен үткәрелә торган V Татарстан башкаласы **ЮГАРЫ УКУ ЙОРТЛАРЫНЫҢ ИҢ ЯХШЫ ЯШЬ УКЫТУЧЫЛАРЫ КОНКУРСЫНЫҢ ФИНАЛЫ УЗДЫ**. Финалда «Мин һәм минем һөнәр» дигән иҗади презентация, конкурс-импровизация һәм «Минем вуз: Универсиаданы каршылап» конкурслары булды. Әлеге мәртәбәле бәйгедә икенче урынны КФУ юридик факультетының дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы кафедрасы ассистенты Михаил Воронин, яулады.

• • • •

Кичә «УНИКС»ның зур концертлар залында Универсиада шәһәрендә яшәүче КФУ студентларының **«ЕЛГА НӘТИҖӘ ЯСАП» ИСЕМЛЕ ГАЛА-КОНЦЕРТЫ УЗДЫ**. Матур җырлар, дәртле биюләрдән торган концертта студентлар үзләренең чын талант ияләре икәнен күрсәтте.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



# Казан - Канадзава яки Япониягә сәяхәт

**Рамил ХАННАНОВ**

Ректор Илшат Гафуров җитәкчелегендәге Казан университеты делегациясе бу көннәрдә эшлекле визит белән Япониядә. Шул уңайдан 29 май безнекеләрне Канадзава университеты президенты, профессор Шин-ичи Накамура тантаналы рәвештә кабул итте.

Казан университеты делегациясе составында икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор Марат Сафиуллин, Физика институтының директор урынбасары Дмитрий Таюрский бар. Канадзава университеты Россия югары уку йортлары арасыннан бер Казан федераль университеты белән хезмәттәшлек итә. Очрашуда шулай ук Кытай, Корея, Таиланд, Кения, Вьетнамнан килгән вәкилләр дә бар иде.

Илшат Гафуров фундамендаль медицина һәм табигый фәннәр юнәлешендә хезмәттәшлек итүнең перспективалары хакында фикер алышуда катнашты. Истәлекле бүләкләр тапшырды.

Хәтерләсәгез, безнең уку йортыбыз Канадзава университеты белән 1998 елдан башлап хезмәттәшлек итә. Шул елның сентябрендә хезмәттәшлек һәм вузлар арасында студентлар алмашы турындагы килешүгә кул куела. Әлеге килешү ике тапкыр (2003 һәм 2008 елларда) озайтыла. Төп хезмәттәшлек түбән температуралар физикасы, ван-флек парамагнетикалары, магнит-төш тәртибе һәм квант сыекчалары физикасы юнәлешләрендә алып барыла. Казан федераль университетының төп партнёры – Канадзава университеты физика факультетының түбән температуралар физикасы лабораториясе (Low Temperature Laboratory), фәнни җитәкче – профессор Харухико Судзуки – 2009 елның 23 апреленнән Казан университетының мактаулы докторы.

Хезмәттәшлек итү елларында профессор Харухико Судзуки Казан университеты галимнәре М.Теплов, М.Таһиров, Д.Таюрский белән берлектә түбән температуралар физикасы юнәлешендә алты фән кандидаты әзерләде. Әлеге яшь белгечләр диссертацияләрен инглиз телендә Канадзава университетында уңышлы гына яклады, бүген КФУда һәм Казанның башка югары уку йортларында эшли. Университетыбызның кырыкка якын вәкиле Япониянең Канадзава университетында белем алды һәм фәнни стажировка үтте.

Конкурс сынауларын узган КФУ студентлары һәм аспирантлары Канадзава университеты белән студентлар алмашу программаларында катнаша ала. Япониядә белем алган студентларыбыз әлеге илнең Студентларга ярдәм итү оешмасының (JASSO) стипендияләренә дә лаек дип табылды.

Кичә, ягъни 30 май көнне КФУ делегациясе Канадзава университеты шәһәрчегендә (кампус) булды, шулай ук бу зур тарихка ия уку йорты оешуга 150 ел тулуга багышланган бәйрәм чараларында катнашты. Бүген һәм иртәгә алар Токионың Физик һәм химик тикшеренүләр институтында (РИКЕН) булачак.

*Матбугат үзәге мәгълүматлары файдаланылды.*

## • Атна ачышы

# Goethe-Institut - Тел үзәге

**Рәдифә ШӘФЫЙКОВА,**
матбугат үзәге хәбәрчесе

29-30 май көннәрендә КФУда Гёте исемендәге Немец мәдәни үзәге делегациясе булды.

Үзәк директоры урынбасары Кристоф Фельдхюз, төбәк координаторы Мария Лукьянчикова һәм Волжск гуманитар институтының филология кафедрасы мөдире Светлана Тахтарова составындагы коллектив безгә әзер проект белән килгән иде: КФУда Гёте-институтның Тел үзәген (Goethe-Institut) булдыру! Бу университетыбыз өчен зур мөмкинлекләр ача. Җитәкчелек тәкъдимне бик теләп кабул итте һәм аны тормышка ашыру юллары турында фикер алышты.

(Тулырак мәгълүматны http://kpfu.ru/main_page?p_cid=8787&p_sub=7 сылтамасы буенча сайттан укый аласыз).



Әмир Фәлыйәхмәтов фотосы

● Бәйге

# Иңнәрнең иң-иңнәре

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

24 май көнне Актлар залында «Иң яхшы академик төркем» конкурсының һәм «Интеллектуаль яз» фестивален җиңүчеләрен бүләкләү тантанасы узды.

Чараны яшьләр сәясәте, социаль мәсьәләләр һәм физкультура-спорт тәрбиясе системасы үсеше департаменты директоры Ю.Виноградова һәм КФУ Президенты М.Сәләховачып җибәрде. Алар «Академик төркемнең иң яхшы кураторы» номинациясендә җиңүчеләрне (Р.Әмирова, юридик факультет, М.Исаева, Экология һәм география институты, Н.Калацкая, Педагогика һәм психология институты, Т.Карпеева, Филология һәм сәнгать институты, Л.Князева, Математика һәм механика институты) тәбрикләде.

«Иң яхшы академик төркем» конкурсында бүләкләү I курслар, кечкенә курслар һәм өлкән курслар номинацияләре буенча булды. I курслар арасында **III урынга** – Математика һәм механика институтыннан **516 ма** төркеме, **II урынга** – юридик факультетның **812 төркеме**, **I урынга** фәлсәфә факультетының **1814 б төркеме** лаек булды.

Кечкенә төркемдә **III урынга** – Идарә итү һәм территориаль үсеш институтыннан **1492 төркем**, **II урынга** – Филология һәм сәнгать институтыннан **05.07-1002 төркем** лаек булды. Төп җиңүне Тарих институтыннан **493 төркем** студентлары яулады.

Зур төркемнәр арасында **III урынны** – Фундаменталь медицина һәм биология институтыннан **170 төркем**, **II урынны** Яшел Үзән филиалыннан **1186 төркем** студентлары алды. «Иң яхшы академик төркем» исеменә, ягъни **I урынга** Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтыннан **986 төркем**, Икътисад һәм финанс институтыннан **120 м төркеме** лаек булды. Әлеге конкурсның төп җиңүчеләре Санкт-Петербург шәһәренә экскурсия белән дә бүләкләнде.

Чараның икенче өлешендә «Интеллектуаль яз» фестивале җиңүчеләрен котладылар. Әлеге чара уку йортыбызда өченче мәртәбә уздырыла. Быел факультет һәм институтлар 6 номинациядә көч сынашты, гомуми нәтиҗәләр буенча өч иң интеллектуаль институт билгеле булды. «Эрудит» номинациясендә өч призлы урынны да **юридик факультет вәкилләре** алды.

«Нәрсә? Кайда? Кайчан?» номинациясендә **I урынга** – тарихчыларның **«СНК» командасы, II урынга** юридик факультетның **«Флеш-рояль»**, Химия институтының **«Колба Дэнчека»**, Физика институтының **«КСВ» командалары** лаек булды. **III урын** фәлсәфә факультетының **«USB» командасына** бирелде. **«Парламент дебатлары»** номинациясендә **фәлсәфә факультеты** җиңүне беркемгә дә бирмәде.

**«Рус телен иң яхшы белүче»** номинациясендә юридик факультет студенты **Светлана Назарова** җиңүче булды. Нәкъ шулай!!! Ә Филология һәм сәнгать институты студентлары **Юлия Конова һәм Гүзәл Хәсәнова II һәм III урынны** алды. «Тарихка кереп кал!» һәм «Казан университеты табышмаклары» номинацияләрендә дә җиңүчеләр билгеләнде.

**«Интеллектуаль яз»** фестиваленең төп җиңүчесе исеменә **Тарих институты** лаек булды, **II урын – юридик факультетка, III урын фәлсәфә факультетына** бирелде.

Җиңүчеләрне тәбриклибез. Алга таба да зур уңышлар телибез!

● Фән дөньясында

# Тотрыклылык көткәндә

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

30-31 май көннәрендә университетыбызда «Европа Союзының икътисады, сәясәте, иҗтимагый тормышы һәм Россия белән мөнәсәбәте: заман таләбе» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция узда.

Европа Союзы моңа кадәр күрелмәгән икътисади кризис фазасын һәм кучеш чорын үтә. Хәзерге вакытта Европа Союзы һәм Европа валютасы хәле дә һәм киләчәк үсеш өчен кайсы векторлар юнәлеше сайланачагы да билгесез. ЕС ның сәяси үлчәме тамырдан үзгәрде һәм дәүләтләр-әгъзалар әчке эшләрдә катнашырга, хакимияттә эшләргә сәләтле, Халыкара валюта фонды оешмасы инициативасы кебек, сайланмаган технократларга зур игътибар бирергә тиеш. Россия-Европа мөнәсәбәтләре мөһим әһәмияткә ия. Бу мөнәсәбәтләр глобаль тотрыксызлык чорында реформалаштыру процессын ничек үтәчәк? Конференциядә менә шушы проблемаларны үз эченә алган сораулар күтәрелде. Сәламләү сүзе белән КФУ ның ЕС –VOICES үзәге җитәкчесе Ирина Кузнецова (Моренко), Порсмута университеты доктору Поул Фленлей һәм НИУВ-ШЭ докторы Джон Раунд чыгыш ясады.

«Россия – ЕС арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең сәяси аспектлары» дип аталган пленар сессиядәге чыгыш ясаучылар арасында чит илләрдән – Бөекбритания, Голландия, Швеция, Германия, Румыниядән, үзебездән – КФУ, Удмуртиянең күренекле галимнәре катнашты. «Европа хокуклары, нормалары һәм аларны җайга салу», «ЕС нын тышкы сәясәте. Икътисади тотрыксызлык чорында Россия-Европа мөнәсәбәтләре» һәм «Студентлар секциясе» дип аталган секцияләр эшләде. Һәр сессия һәм секция эшеннән соң модераторлар тиз арада «түгәрәк өстәл» оештырып, чыгыш ясаучылар белән конференциядә катнашучылар арасында әңгәмә үткәреп алды. Ә йомгаклау дискуссиясендә «Европадагы кризис» дигән темага багышланган эсселар конкурсында җиңүче студентларга бүләкләр тапшырылды. Янымда





утырган Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтының I курс студенты Фәридә Закированың инглиз телендәге чыгышларны колакчынсыз тыңлап утыруына һәм җентекләп язып баруына сокланып, конференциядән алган тәэсирләре турында сорау биргәч, ул татарча җавап бирде: «Миңа үземнең сәяси белемемне күтәрү ошый. Конференциядә чыгыш ясаучы галимнәр сүзен тыңларга яратам. Киләчәктә үземнең позициямне дөрес итеп белдерү юлларын өйрәнәм һәм тормышыбызны яхшы якка үзгәртүдә миннән дә өлеш чыгар дип уйлыйм».

Тотрыклы икътисади хәл кайчанрак булыр? Ил язмышын ни көтә? Әлбәттә, галимнәргә генә түгел, һәммәбезгә уйланырга урын бар.

● Безнең юбиляр

# «Исем бирмәк - бик җаваплы күренеш»

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Университетыбыз галимнәре турында сөйләшүне дәвам итәбез. Бүген сүзебез күренекле тел галиме, Казан төрки-татар ономастика мәктәбенә нигез салучы, Казан дәүләт университетында татар теле фәнен үстерүгә гомерен багышлаган профессор, шагыйрь, публицист Гомәр Фәез улы САТТАРОВ турында.

Гомәр ага 1932 елның май аенда (документларда – 2 июль) Яшел Үзән районы Мулла Иле авылында туа. 1950-1955 елларда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Укуны тәмамлагач, Тобол дәүләт педагогия институтында өлкән укытучы булып эшли. 1959-1962 елларда профессор Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә аспирантура үтә. 1962 елдан 2011 елга кадәр Казан университетының татар теле белеме кафедрасында эшли.

Татар исемнәре дөньясын җентекләп өйрәнгән галим Гомәр Саттаров киң җәмәгатьчелеккә «Исемең матур, кемнәр куйган?», «Татар исемнәре ни сөйли?», «Аталар дөньясына сәяхәт», «Татар исемнәре сүзлеге» һ.б. китаплар, фәнни хезмәтләр аша яхшы таныш. Аның китаплары зур тираж белән чыгарыла һәм шактый кыйммәткә сатыла. Балага исем эзләгәндә, бик күпләр шул хезмәтләргә таяна. 15 меңнән артык татар исемен барлап, аларның мәгънәләрен ачыклаган Гомәр абый Саттаров безнең сорауларга да җавап бирде.

**– Гомәр ага, Сез – исемнәрне җентекләп өйрәнгән төп галимнәрнең берсе. Тагын татар исемфамилияләрен өйрәнүчеләр бармы?**

– Шәкертләрем байтак. 50 дән артык фән кандидаты, 8 фән докторы бар. Ономастика фәне җәелеп бара, эшемне дәвам итүчеләр арасыннан Фирдәвес Гарипова, Флүрә Мәҗитова, Зифа Әхәтова, Миләүшә Вәлиева, Зилинә Хөснуллина һ.б. атап үтәр идем. Минем шәкертләрем арасында Казахстаннан, Тывадан килүчеләр бар. Исемнәр дөньясы киң, хәрәкәтчән, шуңа да иҗат чишмәсе саекмас әле.



**– Мәчетләребездә дин әһелләре исем сайлауга игътибарлы булырга, моңа җитди карарга чакыра. Алар исем кеше язмышын билгели, диләр. Моның белән килешәсезме?**

– Өлешчә килешәм. Психологик яктан кеше үз-үзенә программа яса.

**– Үзегезнең исем турында нәрсә әйтер идегез?**

– Әтием авыл советы сәркатибе булып эшләгән чорында, мин майда туганга күрә, Майс дигән исем тәкъдим иткән. Ярый бабам каршы төшкән, оныгым гомерле булсын дип теләп, Гомәр исемен куйган.

**– Гомәр ага, татар исемнәре тарихын кыскача сөйләп китмәссезме?**

– Һәр халыкта кеше исеменең кызыклы һәм бай тарихы, үзенчәлекле традицияләре, кушу мотивлары бар. Татар исемнәре – халыкның теле, тарихы, мәдәниятенең бер өлеше. Кеше исеменең үзгәрүе җәмгыятьнең социаль үсешенә, культура, идеология эволюциясенә бик тыгыз бәйле. Татар исемнәренең барлыкка килүен һәм үсешен тарихи яссылыкка салсаң, берничә чорга бүләргә мөмкин: мәҗүсилек йолалары тәэсирендә барлыкка килгән борынгы төрки чор, икенчесе – ислам динен кабул иткәч кушыла башлаган исемнәр. Аннары Октябрь революциясеннән соң һәм 1990 еллардан алып бүгенгә кадәр булган чорларны атап була. Һәр этапның үз үзенчәлекләре, сыйфатлары бар.

Борынгы төрки-татар исемнәренең барлыкка килүе мәҗүси ышануларга бәйле. Алар мәҗүсилек йолалары, гореф-гадәтләре йогынтысында килеп чыккан. Мондый исемнәр Тәңрегә, күк, кояшка табынуга корылган. Ә болгарларда бала тугач, кардәшләр белән бергә киңәшләшеп, нинди сыйфатларга ия булуын теләп, төрле явыз көчләрдән саклаарга тырышып, чиннарга ирешүен уйлап, исем биргәннәр.

Шундый кызыклы фактлар да бар. Озак бала тапмыйча интеккән хатын-кызның нарасые дөньяга килгәч, аңа ананың теләкләрен аклау исеме бирелгән. Мәсәлән, вакытында Актаныш районы атамасы Акланыш дигән сүзне йөрткән. Бала тапмый дигән килен көннәрдән бер көнне авырга узып, сабые туса, аңа Акланыш дигән исем бирелгән. Ягъни сабый әнисенең теләген аклаган, аны раслаган. Гарәпләрдән кергән Хөҗҗәт дигән исем дә «аклану, аргумент, факт» дигәнне аңлата. Элекке Президент туган Әнәк авылы исеме дә безнең борынгы йола мотивларына бәйле. Ул «көчек, эт баласы» дигәнне аңлата. Бала тугач, үлмәсен, озак яшәсен, талымсыз үссен, авыруларга бирешмәсен дигән теләктән чыгып, бездә эт баласы исемен бирү гадәте булган. Башкортларда да ул бар, мәсәлән, Көчекбай. Казан ханлыгы башлыгы Мөхәммәд Әмин хан заманында Көбәк исемле бакыр эшләре остасы булган. Көбәк – ул ау эте. Әгерже исеме дә «сунар этләрен караучы» дигәнне аңлата.

Газета укучыларга АКШ президенты Барак Обамага бәйле соңгы вакыттагы сенсацион ачышым да кызыклы булыр дип уйлыйм. Төрки-татарларда Барак исемле кеше булганы билгеле. Барак «йонлач, зур сунар эте» дигән мәгънәгә ия. Бу – борынгы төрки-татар йола исеме, озын һәм йомшак йонлы, затлы нәселле ау эте. Ир бала барак кебек сизгер, затлы булсын дип, аңа шундый исем кушылган. Мишәрләрдә – Бараков, урысларда Баракин фамилияле кешеләр әле дә бар. АКШ президенты Барак Обаманың бабалары – Кения мөселманнары. Барак Обаманың Кениядә яшәүче апасы Зәйтүнә исемле булган. Күрәсез, аларның исемнәре гарәп һәм төрки-татар исемнәренә турыдан-туры бәйле. Обама фамилиясенә бәйле кызыклы фактлар бар. Мирфатыйх Зәкиев үзенең «Татары. Проблемы истории и языка» дип аталган китабында Обама исеменең килеп чыгышы турында фикерләр яза. «Обаба», «Хобаба» Рим императоры Максиминның анасы исеме, ди ул. Бу хатын чыгышы белән алан милләтеннән булырга тиеш. Аланнар иран телләләр. Алан һәм осетиннарны өйрәнгән галим Абаев бу исемнең килеп чыгышын «һиваба» сүзеннән, ягъни «оста тегүче»дән алынган, ди. Төркиләрдә «аб» – ау, «ив», «эв» – өй, йорт, «оба» – эти, әни, бабай мәгънәләренә ия. Димәк, «Обама» әни, йорт дигәнне аңлата. Ислам дине алан кабиләләре, Рим империясе кешеләренә дә йогынты ясаган, безнең төрки-татар традицияләре хәттә көнчыгыш Африка мөселманнарының исем системасына да үтеп кергән дип фаразларга мөмкин.

**– Кызыклы һәм мәгънәле әңгәмәгез өчен рәхмәт! Юбилеегыз котлы булсын, мөхтәрәм Остазыбыз!**

● Тамчы-тамчы тарих

# Пётр I һәм Казан

**Динара ЗИННӘТОВА,**
Журналистика һәм социология факультеты студенты

Бу көннәрдә Россия тарихына радикаль үзгәрешләр алып килгән император Пётр I туганына 340 ел тула.



Үзенең чагыштырмача кыска идарә итү дәверендә ул армия һәм флот оештырырга, күпсанлы мануфактура һәм тау ширкәтләре ачарга, Россиянең беренче музеен – Кунсткамераны һәм «Ведомости» дип аталган беренче рус газетасын булдырырга өлгергән. Пётр I идарә иткән чорда илдә «граждан шрифты» һәм 1700 елда яңа календарь гамәлгә кертелгән. Төньяк сугышында җиңү яулап, Пётр I, Россия җирләрен Балтыйк буе ягыннан киңәйтеп, 1721 елда Россия империясенең беренче императоры исеменә лаек булган.

1722 елның 30 маенда императорның 50 яшьлек юбилеен мәркәзебез Казанда үткәрүе билгеле. Тарихи чыганакларга караганда, бәйрәм бер атнадан артык дәвам иткән. Казан тарихында Пётр I гә бәйле булган тагын берничә кызыклы факт:

- 1708 елда император Казан адмиралтейrichtствосын оештыра. Үзенең 112 ел эшчәнлеге дәверенендә әлеге адмиралтейство Каспий флоты өчен 400 гә якын кораб җитештерә;
- Пётр I гә чиксез хөрмәтен белдереп, 1722 елда Казанның эре сукно мануфактурасы җитәкчесе Иван Афанасьевич Михляев Пётр һәм Павел соборын төзетә. Әлеге тарихи архитектура бүгенге Казанның Муса Җәлил урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан. Элек бу урам Пётр һәм Павел исемен йөрткән булган;
- Казанда Пётр I гә бәйле блуган атагын бер архитектура истәлеге – Дряблов йорты башкалабызның иң борынгы биналарыннан санала. 1722 елда император Петр I биредә кунак булуы билгеле.
- 50 яшен Казанда гөрләтеп үткәргәннән соң, император Әстерханга юнәлә, аның юлы борынгы Болгар хәрабәләре аша үтә. Пётр I шул вакытларда ук әлеге тарихи истәлекләрнең җитешсез хәлдә булуларына игътибар итә һәм шул ук елның 2 июлендә Әстерханнан Казанга Болгардагы биналарны төзекләндерү һәм саклау турында фәрман юллый.

Һичшиксез, Пётр I алдынгы карашлы, шактый белемле зур шәхес булган. Кечкенәдән ул төрле фәннәр, чит илләр тормышы белән кызыксынган. Белемгә омтылыш һәм көчле амбицияләр бүген дә җәмгыять үсешендә зур роль уйный. Тарихыбызны ныклы нигез итеп, яңа үрләр яуларга вакыт.

● Абитуриент, синең өчен!

# Кем булырга?

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

Алда – имтиханнар, ә алар белән бергә борчу-мәшәкатьләр дә килә. Шулай итеп, күпме укучы, аларның әти-әниләре алдында нинди һөнәрне сайларга диган бик катлаулы сорау барлыкка килә.




Әлеге авыр чорны ничек уңышлы итеп үтәргә соң? Хәзерге заманда киңәш-тәкъдимнәрне санап бетерерлек түгел. Хәтта туган көнгә карап та үзеңә туры килгән һөнәрне билгеләп була икән. Россиянең танылган экстрасенсы Александр Литвин шул уңайдан яшьләргә дөрес юл күрсәтә. «Битва экстарсенсов – 6» тапшыруы җиңүчесе, энергетика һәм аның безнең тормышка тәэсире буенча белгеч Александр Литвин имтиханга әзерлек һәм аны тапшыру чорына үз тәкъдимнәрен җиткерә. Алар безнең газетаны укучылар өчен дә кызыклы булыр дип уйлыйбыз.

Күп кенә мәктәп укучылары һөнәр сайлауны уку йортын сайлауга кайтарып калдыра. Һөнәр – безне реальләштерә торган төп чара, ул дөрес сайланса гына, үзең өчен дә, җәмгыять өчен дә файдалы шәхес буласың. Бу мәсьәләне хәл итүдә ата-аналар аеруча зур роль башкара: алар я тулысынча баланың киләчәген хәл итә, я бөтенләй, кая телисең, шунда кер, дип, баланы контрольдән югалта. Кайбер кешеләрнең эчке сиземләве яхшы, ләкин алар аны дөрес файдаланмаска мөмкин. Кемнәрдер кечкенәдән үк үзенең кем булачагын күрә, бер максат итеп куя һәм шуңа ирешә дә.

Александр Литвин кешенең нинди көндә һәм кайда тутуына карап, аның һөнәри мөмкинлекләрен әйтеп бирә.

**8 август – 7 сентябрь:** агрономия һәм туфракны өйрәнү; бөртекле культуралар үстерү, эшкәртү; финанс оешмаларында, банкларда, IT технология үзәкләрендә эшләү; журналистика – финанс эшчәнлеген яктырту; азык-төлек сәнәгате; җиләк-җимеш кайнатмалары һәм бал җитештерү; театр, музыка, банк һәм имминиятләштерү эшчәнлеге; идарә итү; әдәбият һәм журналистика; армиядә тәрбия эшләре; төзелеш һәм архитектура; файдалы казылмалар табу.

**8 сентябрь – 8 октябрь:** аудит; театр һәм кино өлкәсендә тәнкыйтьче; продуктлар эшкәртү һәм саклау, журналистика; ресторан бизнесы, кулинария.

**9 октябрь – 7 ноябрь:** туризм, коллектив ял һәм күңел ачу чараларын оештыру; оптика; җиһаз ясау, фото, видео һәм аудио аппаратура ясау һәм әлеге өлкә белән бәйле иҗат эшләре; көнкүреш техникасын, авто һәм мототранспорт ремонтлау; хәрби медицина, хирургия, беренче ярдәм хезмәткәре; умартачылык; агрономия; баш киемнәре дизайны; ветеринария, зоология.

**8 ноябрь – 7 декабрь:** диңгез һәм су транспорты дизайны; экология; йорт һәм коммуналь хезмәтләр өлкәсе; автомобиль буенча белгеч; туризм һәм география; хәрби-диңгез флоты.

**8 декабрь – 5 гыйнвар:** психология, дини укулар, дин тарихы, дини эшчәнлек; диңгез һәм су транспорты; чит телләр буенча белгеч.

**6 гыйнвар – 4 февраль:** гаилә мөнәсәбәте психологиясе; психиатрия; санитар-эпидемиологик контроль, суыткыч технологиясе; гидрогеология һәм су җиһазларын проектлаштыру; театраль эшчәнлек; авыл хуҗалыгы; журналистика һәм әдәбият.

**5 февраль – 5 март:** армиядә, салым инспекциясендә, полициядә юридик эшчәнлек; медицина өлкәсе; МЧС хезмәткәре, коткаручы.

**6 март – 5 апрель:** театр эшчәнлеге; нәшрият эше; журналистика, филология; көнчыгыш телләр буенча тәрҗемәчеләр; дипломатия.

**6 апрель – 5 май:** муниципаль идарә; прокуратурада юридикэшчәнлек;агросәнәгать комплексы; архитектура һәм төзелеш; скульптура.

**6 май – 5 июнь:** инглиз теле тәрҗемәчеләре; куркынычсызлык хезмәте, тән сакчылары; тикшерүчеләр; терапевтик медицина, кардиология; ландшафт һәм кием дизайны; финанслар һәм кредит; урман хуҗалыгы хезмәткәрләре; музыка.

**6 июнь – 7 июль:** аучылык, балыкчылык; физик тәрбия; экология, туризм, агачтан өй җиһазлары ясау; халык авыз иҗаты буенча белгеч.

**8 июль – 7 август:** театр һәм режиссура; сынлы сәнгать, рәсем ясау; мәктәпкәчә кадәр белем бирү; агрономия; офтальмология; PR һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләү.

Бу мәгълүмат хәтта югары уку йортын тәмамлаучылар өчен дә зур ярдәм булырга мөмкин, чөнки фактлар студентларның күбесенең үз һөнәре буенча эшләмәве турында сөйли. Иң мөһиме: үзегезне башкалар белән чагыштырмагыз, үзегез булып кала белегез. Үзеңне үзең белән чагыштыру тагын да зуррак уңышка китерә, чөнки үз мөмкинлекләреңне син бик яхшы беләсең. Максатларыңның кайсыларына ирешелгән, әле нинди планнарың бар? Яхшылап уйла, нәтиҗәсе горурланырлык булсын!

*«Комсомольская правда» газетасы мәгълүматлары файдаланылды.*

● Кечкенә галимнәр

# Кадрия ШАКИРОВА: «Суфия Гобәйдуллина рояле - минеке...»

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Бүген сәхифәбез кунагы – КФУ ның Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты математиканы һәм информатиканы укыту методикалары һәм технологияләре кафедрасы мөдире Кадрия Бари кызы ШАКИРОВА.





*«Һәрбер әти-әнигә хас булган сыйфат ул – баласын шәхес итеп күрә белү, мөмкин булганча төрле яклап үстерергә теләүдер инде. Минем әти-әнием дә искәрмә түгел, алар безне кечкенәдән максатчан булырга өйрәттеләр... Бер вакыт, мине – кечкенә Кадрияне 6 яшьтә музыка мәктәбенә укырга бирделәр! Ишетеп отып алу сәләте бар,бәлки җырчы булып китәр дип тә уйлаганнардыр. Шулай итеп, мин алты яшемнән скрипкада уйный башладым. Ләкин скрипка мине әллә никадәр үзенә җәлеп итмәгән,күрәмсең, миңа рояль кирәк иде. Ул вакытта рояльләр дә бөтен кешедә булмый, булса да сирәк иде. Әле дә хәтерлим, миңа әти-әнием шундый зур рояль алып кайтты. Ул да гади генә түгел, танылган композитор Суфия Гобәйдуллинаныкы иде. Уен коралының хезмәте уйнау гына түгел, ә кунакка килгән балаларны, урын җитмәгәндә, шунда түшәк ясап йокларга яткырудан да гыйбарәт иде. Ләкин музыка белән мавыгуым озак дәвам итмәде, 3 нче класста инде туктадым. Әле бервакыт скрипкамның таякчыгы (смычок) кыш көне кар астында калган иде, яз җиткәч, бер мәлне килеп чыкмасынмы! Бер җиренә дә зыян килмәгән иде. Вакытлар үтә торды... Соңрак инде музыка белән түгел, ә төгәл фәннәрдән математика белән кызыксына башладым... Музыка ничектер читтәрәк калды. Рояльне дә, артык күп урын биләп торганга, сораучы башка бер гаиләгә бирдек. Кем белә, бәлки шул юнәлештә кызыксынуымны дәвам итсәм, берәр танылган музыка белгече дә булып киткән булыр идем...».*

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

• оформление по договору,
• гибкий график работы, возможность совмещения,
• оплата своевременная, обучение за счет компании,
• **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),
Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.
**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

● Соңгы кыңгырау

# Эшләргәме, әллә яшәргә иренәбезме?..

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче

25 май... Менә тагын мәктәпләрдә, вузларда соңгы кыңгырау чылтырады. Укучылар кая укырга керергә белми аптыраса, студентларны эшкә урнашу мәсьәләсе чолгап алгандыр.





Без бар нәрсә дә алга киткән, үсеш алган чор – XXI гасырда яшибез. Бар да үсештә, яңарышта кебек, ләкин һәр кешенең, шулай ук яшьләрнең дә, үз проблемалары бик күп. Әлбәттә, без – татар яшьләрен дә киләчәк, бигрәк тә демография мәсьәләләре борчый. Татар халкы 100 елдан соң бүгенге санда калырмы-юкмы, дигән сорау кискен тора. Дини тәрбия, мәгариф өлкәсендә дә хәл итәсе сораулар бар. Үзебезнең авылда гына кырыктан артык буйдак ир-егетне күреп куркып, шомланып каласың. Кайда ялгышлык киткән соң? Ник гаилә, алай гына да түгел, ил тегәге булырдай ирләребез ялгыз?! Авылда үз көче белән яшәп көн күргән егетләр, шәһәрнекеләрдән киммени? Монда уйланырга урын күп.

Хәзерге заман егетләре генә түгел, гомумән, яшьләр югалып калды бугай бу дөньяда. Кайсы юл белән барырга белми аптыраган кебек миңа. Нинди юл җайлырак, күп табыш китерә – яшьләр шул якны карый, авыр эштән курка. Бу базар икътисадына да бәйле, чөнки ул кешеләрне үзе өчен генә яшәргә өйрәтә. Бар нәрсә дә акчага бәйле, алар рухи байлык, мирастан читләшә. Яшьләр гаилә корырга, балалар тәрбияләргә ашыкмый. Үстерсәләр дә, бер бала белән чикләнәләр. Шуннан демография мәсьәләләре калкып чыга. Күп кенә яшьтәшләремнән, авылдашларымнан сораганым бар: яшьләрне нинди проблемалар борчый, ник авыллардан качалар? Күбесе моны эшләр урын булмау яки хезмәт хакының түбән булуы белән аңлата, ә акча булмагач, яшәве җиңел түгел. Шәһәрдә ял итү өчен бөтен шартлар да тудырылган, район, авылларда исә алар бик сирәк, дигән җаваплар да ишетергә туры килде. Эшләр эше, шөгыле булмаган кеше алкоголь, наркотик белән бәйләнә, килеп туган буш вакытын шулай «файдалы» үткәрергә уйлап, чоңгылга төшкәнен сизми дә кала. Күңел ачу, дискотекаларны җыелып эчүгә генә корганнарын күреп, күңел әрни.

«Күбесенә, авылга кайткан очракта, алтын таулар вәгъдә итәләр, ләкин кайтып эшли башлагач, алар күренми», – дип авыр сулап куйды бер танышым. «Шәһәрдә аз булса да түлиләр, шуңа күрә авылны мактап, шәһәрдә тора яшьләр», – ди ул. «Авыл егетенә кем кияүгә чыксын инде?» – дип зарланучылар да юк түгел. Ә бит шәһәрне туендыручы – ул авыл. Анда яшәве дә җиңелрәк, миңа калса. Шәһәрдәге бер танышым, мәсәлән, унбиш мең хезмәт хакы алып эшли. Күп дип әйтеп булмый, ә бүлә башласаң, бөтенләй дә калмый. Ун меңгә фатир алып тору, айга мең сум тирәсе юлга тоту, ашауэчүне санасаң, эштән соңгы тормышка калмый да диярлек. Авыл өчен бу акча ай буена тулысынча җитә.

Мин, мәсәлән, авылда яшәүгә каршы килүчеләрдән түгел. Үзем яратып эшли торган эшем, гаиләм белән торыр урыным булса, нигә калмаска ди әле?! Район үзәге булса, әлбәттә, тагын да яхшырак. Шәхсән мине, яшь белгеч буларак, эшкә кайткан укытучыга бирелә торган грант, торак мәсьәләләре буенча программалар кызыксындыра. Мондый программалар башка өлкәләрдә, бигрәк тә авыл хуҗалыгында булса, яшьләрне җәлеп итү өчен әйбәт булыр иде. Яшьләрнең шактый өлешенә тәвәккәллек җитми, аларга барысы да бүген, күпләп, бирьюлы кирәк. Минемчә, яшьләр өчен бу хөкүмәт программалары – зур ярдәм. Шушы кредит яки ссуда акчаларын урынлы куллана белү шарт. Дөрес, күбесен «кәгазь боткасы» куркыта, шуңа ашкынмыйлар. Шәһәр йортының бер бүлмәсендә тулып ятып, дипломлы белгеч була торып, ишегалды себерүче яки сатучы булып эшли, тик авылның иркен кырларына гына ашыкмый ул. Авылда яшәргә түгел, ә эшләргә курка бүгенге яшь буын. Шуннан соң эш юк дип зарлану дөрес булырмы икән?!.

● Мәсьәләгә бер караш

# Яшьләр колагына

**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
Филология һәм сәнгать институтының
белем бирү бүлеге җитәкчесе




Өйләнү, кияүгә чыгу, тормыш кору... Кеше тормышында була торган иң мөһим, иң күңелле мизгелләр..



Тормыш корганга кадәр егет белән кыз очрашып йөри. Билгеле, кемдер үлеп гашыйк була; кемдер «моның холык-фигыле күркәм» дип, гомерлек пар сайлый; кемдер «моның кулыннан эш килә, моның белән тормыш итәргә була» дип фикерли; кемдер «әти-әниләре бай, мул тормышта яшәрмен» дигән максатны алга куеп эш итә.

Билгеле, соңрак мөнәсәбәтләр катлаулана төшә. Кайберәүләр матур гына җитәкләшеп төнге урамнар буйлап йөри, кайберәүләр «ду» килеп кычкырыша, яңадан дуслаша. Ә кайберәүләр ир һәм хатын роленә кереп яши башлый. Рус телендә «гражданский брак» дип аталган бу «гаиләләр» чын мәгънәсендә брак булып чыга. (Брак – это продукция (товар, услуга), не соответствующая заявленному качеству). Әти-әниләр, туганнар ризалыгын алмый гына, гореф-гадәтләрне читкә куеп, «әйдә, яшәп карыйк әле», дигән принципны алга сөреп корылган мөнәсәбәтләрне сыйфатсыз, ярақсыз товар белән тиңләвем юкка түгел, җәмәгать... Мондый «гаиләләрнең» тотрыксыз булуы турында күп сөйләп, аңлатып торуның кирәге юктыр.

Очрашулардан соң кайберәүләр тиешенчә никах, туй белән мөнәсәбәтләрен ныгытырга тели. (Әйтергә онытканмын, бу очрашулар бер ай да, бер ел да, 5 ел да булырга мөмкин. Кем күпме булдыра ала инде).




Туйны берәүләр лимузиннарда, 150ләп кунак җыеп үткәрә. Билгеле, андый туйларга туганнар гына түгел, дәрәҗәле түрәләр, бай танышлар чакырыла. Яшьләргә фатир да бирелә, машина да бүләк ителә, сәяхәт итү өчен юллама да тоттырыла. Яшьләр шат. Шат булмыйни! Кайда яшәрбез, ни ашарбыз дип кайгырасы юк. Фатир җиһазландырылган, акчалы эш табылган... Кыскасы, тырышканнар әти-әниләр. Ә берәүләр иң якын туганнарын чакыралар да тыйнак кына туй үткәрәләр. Ә кайберләре: «Шулкадәр кеше җыеп, акча түккәнче!.. – дип, ЗАГСка барып кайта да – вәссәлам.

Шулай итеп тормыш башланып китә... Әйткәнемчә, кемдер затлы фатирларда, кемдер тәлинкә-кашык сатып алып башлап җибәрә тормышны. Берәүләр «моны алабыз, тегене алабыз», дип планнар кора, аны алгач, кош тоткандай бер ай сөенеп йөри. Монысы – иң яхшы вариант. Әле башкача да булырга мөмкин. Моңа кадәр егет күзләренә карап, «яратам», дип пышылдаган иреннәр «акча юк, акча җитми, тегене хочу, бу кирәк, әнә теге моны алган», дигән бертөрле сүзләр генә кабатлый башларга мөмкин.

Билгеле инде, теге затлы фатирларда яшәүчеләрнең проблемалары, уйлары башка, үзгә. Алар шулай ук үзара мөнәсәбәтләрне җайга салырга маташалар.

Тагын тегеләренә дә, боларына да охшамаган гаиләләр бар... Билгеле, болары да тормышны беренчеләре кебек бер кашык, бер тәлинкәдән башлап җибәргән. Әмма беренчеләрдән аермалы буларак, алар бер-берсен ярты сүздән аңлый, уй-фикерләре уртак, максатлары бер. Хатын кеше ирен юк кына бер эше өчен дә мактап туя алмый, ә ир кеше, шуңа нәни баладай куанып, таулар күчерергә әзер. Алар бергәләшеп, тормышыбыз матур булсын дип, булганына шөкер итеп, сөенеп яшиләр. Бу гаиләдә нигәдер хатын да ирне «миңа чәшке тун кирәк, әнә тегенеңхатыныҗиңелмашинада җилдерә», дип тинтерәтми. Тормыш ничектер үз агымына ага, көтелмәгән җирдән туны да, фатиры да, башкасы да барлыкка килә. Ходай шулай булганына шөкер итеп, берберсен яратып яшәүчеләргә күбрәк бирә, күрәмсең...

Әйткәнемчә, тормыш корганга кадәр егет белән кыз очрашып йөри. Иреңнең нинди рәк ир, хатыныңның нинди рәк хатын буласын очрашып йөргәндә үк чамалап була... Мөнәсәбәтләрне рәсмиләштерергә, тормыш корырга җыенганчы күзләреңне тагын бер кат зур итеп ачып кара. Аннан: «Ник син тегенди?! Ник син мондый?!» – дип җикеренеп йөрмә! Чөнки хәзер элеккеге замандагы кебек димләп, көчләп өйләндерү, кияүгә бирү юк. Сез бер-берегезне меңләгән, миллионлаган кеше арасыннан табып, сайлап аласыз. Билгеле, «мәхәббәтнең күзе сукыр», диләр, әмма гомерлек юлдаш сайлаганда бераз игътибарлырак булу кирәктер...

Әгәр син егет кеше булып та чисталык, пөхтәлек яратасың икән, кыз яшәгән йортка, бүлмәгә игътибар ит. Булачак хатыныңның тәмле ризыклар пешереп, синең яныңда бөтерелеп йөрүен телисең икән, аларга кунака кил. Синең яныңда әнисе бөтерелеп йөреп, ул синең кочагыңда телевизор карап утыра икән, үзең шуннан нәтиҗә ясa. Әгәр син һәр тиенеңне санап торасың икән, аның килеш-килбәтенә дә игътибар итәргә онытма. Атна саен чәч буята, тырнакларын бер сантиметрга үстерә, көн саен яңа кием алыштыра, җиңел машиналарда гына йөрүне хуп күрә икән, тагын бер кат ныклап уйла. Чөнки син аны үзгәртә алмаячаксың. Кияүгә чыккач та ул нәкъ шулай киенәчәк, буяначак. Ә син аның теләк-хыялларын тормышка ашырырга әзерме, дөресерәге, мөмкинлегең бармы?!. Әгәр син көнче күбәләк икән, егетләр янында боргалануына – күз, сөйләшүенә колак салырга онытма. Берүк башка егетләрнең дә синең кызың турында ни сөйләвенә игътибар ит. Алар кайчак күзлек кеби, син күреп бетермәгән нәрсәләрне дә күрергә ярдәм итәләр.

Кыз кешеләргә дә оста разведчик булу комачауламый. Әгәр сиңа исерек ир белән яшәү ошамый икән, егет вакытта ук аның мәҗлесләрдә ничә тапкыр рюмка күтәрүенә күз сал. Тәмәке исенә аллергия икән, «өйләнгәч, бала тугач ташлар әле, ташлаттырырмын әле», дип хыялланма да. Шулай ук әти-әнисенең кем булуына, ничек яшәвенә игътибар ит. Очын очка ялгап яшәп ятучы әти-әниләр улына хан сарайлары салып, машиналар алып бирмәячәк. Әгәр син ирең белән тормыш төбеннән иңгә инне куеп күтәрелергә әзер икән, рәхим ит. Әмма аның нинди гаиләдән чыкканын күрә торып, «миңа теге кирәк, бу кирәк», дип беренче көннәрдән үк аның җанын телгәләмә! Инде синдә дә көнчелек кортлары шактый икән, башка кызлар белән нинди мөнәсәбәттә булуына кара. Әгәр ул теләсә нинди кызны синең янда ук кочып ала, бертуктаусыз смслар яза икән, үзең шуннан нәтиҗәләр ясa. Горур бул, егет артыннан тагылып йөрмә, үзеңнән көләргә, мыскыл итәргә ирек куйма. Әгәр аның шундыйрак «асыл» гадәтләре бар икән, онып син аны. Ул сине бәхетле итмәячәк.

Әйе, яшьләр бер-берсен меңләгән, миллионлаган кеше арасыннан табып, сайлап ала. Сайлау дигәннән... Сайлаганда, бераз үзеңә дә игътибар итәргә онытма! Син үзең нинди?! Үзең идеал егет, идеал кыз эзлисең, ә үзең?!. Артык сайланып та йөрмә, пенсия яшенә җитүең ихтимал. Син сайланган арада яшьтәшләрең өйләнеп, кияүгә чыгып бетә, тормыш кору шансы көннән-көн азая. «Сайлаган сазга, очраган тазга», дигән әйтемне онытып җибәрмә. Барлык яктан да килгән, идеал кешеләр юк. Тирәндәге егетләр, кызлар арасыннан сине яратканын, хөрмәт иткәнен сайласаң, үкенмәссең.

...Нәселенә генә түгел, милләтенә дә игътибар итәргә кушкан бабайлар. Кан кушмаска кирәклеген ассызыклаган алар. `Һәр милләтнең үзенә генә хас гореф-гадәтләре, ышанулары бар. Һәр як та аны сакларга, буыннан буынга калдырырга тели. Татарлар ислам дине кануннары буенча никахлаша, бала тугач, аңа исем куша, сөннәткә утырта. Руслар христиан дине кануннары буенча яши: чиркәүгә барып никахлаша, бала чукындыра, йорт почмагына икона элеп куя. Ике бөек милләт, кыйблалар төрле, гадәтләр башка. Гаиләдә низаглар буласы көн кебек ачык. Ике йөрәк кушылды дип кенә гасырлар буена килгән йолаларны, гореф-гадәтләрне үзгәртеп, диннән баш тартып булмый... Кан тарта...

Әгәр тормышта ир үз урынында, хатын үз урынында булса, өйләнешергә куркып йөрүчеләрнең саны азаер, бәхетле гаиләләрнең саны бермә-бер артыр иде...

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.